лексической единицей, а слова, образованные с их помощью нужно считать сложными словами.

В годы независимости бывших союзных республик появилось больше возможностей для общения деятелей науки, в частности лингвистов. Современные технологии способствуют быстрому обмену информацией о результатах научных исследований, опубликованных книгах и статьях.

Приведенные выше малочисленные примеры служат конкретным доказательством того, что туркменские ученые лингвисты всегда тесно сотрудничали со своими татарскими коллегами и всегда были в курсе их достижений в мире науки. А исследования наших ученых внесут свой посильный вклад в развитие мировой тюркологии.

**Литература**

1. Соегов, М. Первичные формы деепричастия в современных огузских языках / М. Соегов. – Ашгабат, 1994.
2. Таганова, М.А. Изучение словообразовательных гнезд в туркменском языке // Актуальные вопросы тюркологических исследований. К 180-летию кафедры тюркской филологии Санкт-Петербургского государственного университета / Сб. Статей под ред. Н.Н. Телицина, Й.Н. Шена. – СПб.: СПбГУ, 2016. – С.100-108.
3. Atanyýazow, S.Türkmen diliniň sözköki sözlügi / S, Atanyýazow – Aşgabat, 2004.
4. Nurmuhammedow, A. Türkmen dilinde söz basymy (Eksperimental-fonetik derňew) / A. Nurmuhammedow. – Aşgabat, 2012.
5. Türkmen diliniň grammatikasy. Morfologiýa. – Aşgabat, 1999.

***Тимерханов Айнур Әхәт улы***

***Сәфәров Ринат Таһир улы***

ТР ФА нең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ОРФОГРАФИЯСЕНЕҢ КАЙБЕР АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

*Мәкалә хәзерге татар теленең гамәлдәге орфографиясендә булган кайбер кимчелекләрне янә бер кат күз уңыннан үткәреп, аларны хәл итү юлларын эзләүгә багышлана. Авторлар бүгенге шартларда орфографиягә нинди дер җитди төзәтмәләр тәкъдим итүнең (қ, ғ һәм ў хәрефләрен кертү, е, ё, ю, я хәрефләрен аерып, йы, йе, йо, йу, йү, йа, йә шәкелендә бирү) бик катлаулы мәсьәлә булуын, аңа үзгәрешләр кертүнең фәнни булудан бигрәк сәяси һәм икътисади бер проблема икәненә басым ясыйлар.*

**Ключевые слова**: *татарский язык, орфография, орфоэпия, языковая политика, латиница, кириллица.*

*The article is devoted to the analysis of some limitations of the present Tatar orthography and the ways of overcoming them. The authors underline the idea that introducing changes to the contemporary Tatar orthography under the present conditions (such as new letters қ, [q], ғ [ğ] and ў [w]; offering to use the letters е [ye], ё [yo], ю [yu], я [ya] in the form of combination of two letters: йы [yı], йе [ye], йо [yo], йу [yu], йү [yü], йа [ya], йә [yä]) is an extremely complicated matter. They believe that it is a political and economic issue rather than the linguistic one.*

**Key words**: *Tatar, orthography, orthoepy, language policy, Latin script, Cyrillic script.*

Матбугат битләрендә татар орфографиясе өлкәсендә электән хәл ителми килгән проблемаларга бәйле борчулы мәкаләләр әледән-әле басыла тора [мәс.: Хатипов, 2015]. Мондый чыгышлар, фәнни яңалыгы белән әллә ни аерылып тормаса да, гади укучы, галимнәр, шулай ук тел мәсьәләләре өчен азмы-күпме җаваплы дәүләт структуралары вәкилләренең игътибарыннан читтә калмый. Әлеге мәсьәләләр турыдан-туры безнең көндәлек эшебезгә бәйле буганлыктан, мәкаләбездә аерым фикерләрбез белән уртаклашып китүне кирәк таптык.

Татар теленең гамәлдәге алфавиты һәм орфографиясе тел үзенчәлекләрен тулысынча исәпкә алып бетерми. Бу факт тел белән кызыксынган һәркемгә мәгълүм. 1939 елда татар язуы латин хәрефләреннән кириллицага күчерелә, 1941 елда шушы кириллицига нигезләнгән яңа орфография кабул ителә. Шул ук вакытта орфография кагыйдәләре дә эшләнеп гамәлгә кертелә. Ни кадәр генә гаҗәп булмасын, татарча язуда без бүгенгәчә әнә шул рәсми кабул ителгән кагыйдәләргә таянабыз.

Инде 1950 еллар уртасыннан алып, бу орфографиянең кимчелекләре турында газета-журналларда, фәнни даирәдә бүгенгәчә дәвам итеп килгән кызу бәхәс башлана. Бу бәхәснең үзәгендә, башлыча, әйтелештә булган, ләкин язуда аерым билгеләр белән белдерелмәгән арткы рәт [қ], [ғ] һәм [ў] тартык авазлары тора.

Бу бәхәснең нәтиҗәсе буларак, 1989 елда *қ, ғ* һәм *ў* хәрефләрен дә үз эченә алган яңа «Татар әдәби теле алфавиты» кабул ителә һәм ул Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Указы белән раслана да. Әмма 1990 елларда җәмәгатьчелектә киң таралыш алган «яңалифкә кайту», «латин графикасына күчү» фикерләре бу алфавитны гамәлкә ашырырга комачау итә.

Берникадәр вакыт узу белән сәяси яссылыкта да каршылыклар килеп туа. Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы Законы Россиядә яшәгән халыкларга, рус-кирил алфавитына нигезләнгән язудан тыш, башка төр алфавитлар кабул итүне тыя. Аерым сәясәтчеләр тарафыннан Россия территориясендә үзгә алфавит куллану хәтта илнең бөтенлегенә һәм куркынычсызлыгына яный дигән фикерләр дә яңгырый.

2012 елда Дәүләт Советының 36 нчы утырышында депутатлар тарафыннан «Татарстан Республикасында татар теленең дәүләт теле буларак кулланылышы турында»гы Закон кабул ителде. Бу закон нигезендә татар теленең гамәлдәге орфографиясе калдырылды. Шул ук вакытта, дәүләт органнарына латин һәм гарәп графикасындагы алфавит нигезендә хат юллау яки башкача мөрәҗәгать итү мөмкинлеге дә каралды. Шулай итеп, рәсми кабул ителгән язу элеккеге алфавитка нигезләнгән булып кала бирә. Димәк, гражданнар белән аралашуда дәүләт бары рәсми алфавитка таянып кына эш йөртә ала.

Күренгәнчә, дистәләгән еллар буе татар алфавиты һәм орфографиясенә мөнәсәбәтле бәхәс һәм аның тирәсендәге ыгы-зыгы мәсьәләнең бик катлаулы һәм, кайберәүләр уйлаганча, «тавышсыз-тынсыз, ипләп кенә» хәл ителә торган түгеллеген күрсәтә.

Татар теленең графикасы, орфографиясе, орфоэпиясе мәсьәләләре Г.Х. Алпаров, Л. Җәләй, Х.Р. Курбатов, М.З. Зәкиев, Ф.А. Ганиев, Х.Х. Сәлимов, Р.С. Абдуллина, Ш.Н. Асылгәрәев һ. б. бик күпләрнең хезмәтләрендә төрле яссылыкта, төрле аспектларда яктыртыла. Аларны хәл итү юллары да тәкъдим ителә. Ш.Н. Асылгәрәев «Татар теленең алфавиты һәм орфографиясе турында» исемле мәкаләсендә бу мәсьәләләрне янә күз уңыннан үткәреп, гомумиләштереп, мисаллар белән ныгытып шәрехләп бирә [Асылгәрәев, 2009]. Орфография мәсьәләләре безнең чыгышларыбызда да шактый киң итеп яктыртылган иде [Тимерханов, 2011].

Проблеманың гомуми контекстыннан бары тик бер генә күренешне аерып алып, ягъни язуда **я** ны **йа/йә** шәкелендә «гади» генә ачып бирү фикерен алга сөрү (кара: Хатипов, 2015), безнеңчә, – орфография мәсьәләсенә берьяклы якын килү. Әйе, зурдан кубып, әллә кая китеп булмый. Андый тәҗрибә булды инде. Илдәге бүгенге сәяси-икътисади вазгыять тә моңа булышлык итми. Шуңа да карамастан, бу юнәлештә эш дәвам иттерелергә тиеш.

Вазгыятьне төптән аңлаган хәлдә, эш язуда аерым билгеләре булмаган [қ], [ғ] һәм [ў] авазлары мәсьәләсе яки аерым сүзләрне язу рәвешен үзгәртү белән генә чикләнми. Әйтелеш белән язылыш арасындагы аерымлыкларга бәйле рәвештә татар орфографиясе өлкәсендә тагын әллә никадәр хәл ителәсе мәсьәләләр барлыгы ачыклана, төгәлрәге аларның барлыгын тәкрарларга туры килә. Әйтик, **е, ю, я** рус хәрефләрен татар сүзләрендә [йы], [йе] [йу] [йү] [йа] [йә] хәреф тезмәләре аша ачып бирү яки бирмәү мәсьәләсе. Мисал өчен: *йалкын, йәм, йефәк, йумарт, йул, йүкә, йырак* һ.б. Әйтик, **я** ымлыгын **йә** хәрефләр тезмәсе аша бирәбез икән, эзлекле рәвештә шундый бар очракларны язуда бертөсле хәл итәргә тиеш булабыз.

Телебездә аерым сүз яки бер төркем сүзләрнең язылышына бәйле четерекле мисаллар бик күп. Алынмалар белән хәл тагын да катлаулана. Менә, мәсәлән, *меню* сүзе белән нәрсә эшләргә? Алдагы фикерне дәвам

итеп, аны ничек язарга тиешбез: *менйу*мы, *менйү*ме? Беренчесендә **н**ның йомшаклыгы чагылмый кала. Икенчесендә **у** чагылмый. Мондый язылыш орфоэпиядә ничек чагылачак? Әле кушымчалар кушып карасак... Ә вакытлы матбугатта *менюда*, *менюсында,* сирәгрәк *менюында* дип язу гадәткә кергән. Орфографиядәге төрлелек сүзлекләрдә дә күзәтелә.

Язылышларын «татарчалаштырган» очракта *юбилей, юмор, ямб* һәм шуныңише башка күп кенә сүзләр, бигрәк тә интернациональ саналган терминнар, бөтенләй үзгә һәм чит кебек кабул ителә башлый. Моның безгә файдасы буламы?! Ә зарары бар: сүзнең визуаль һәм яңгыраш образы югала, бердәйлек принцибы бозыла һ.б.

Авазлар белән хәрефләрнең туры килмәгән очраклары бихисап. Мәсәлән, *музыка* сүзен татарча дөрес уку өчен, [музыйка] дип язарга я махсус билге уйлап табарга кирәк була. Димәк, **ы**да да проблема бар. Шул ук хәл русчадан кергән *вагон* сүзендәге **о** авазында һ. б. ш.

Кушымчаларның йомшак-каты вариантларын кушу мәсьәләсе дә тел белән эш иткән галимнәрнең һәрдаим игътибар үзәгендә кала бирә. *Станция* рус теле аша кергән. Анда ул сүз каты әйтелә ([станцыя]), чөнки **ц**ның табигате шундый. Ә татарчага килгәндә, матбугат битләрендә, беркатлы гына уйлап, аны сингармонизм законына буйсындыру күзәтелә. Ә *кальга, фаҗига* кебек сүзләргә нинди кушымча ялгарга икән?! Әлеге сүзләрне матур әдәбиятта һәм публицистикада куллану очраклары аларның йомшак кушымча алуларын күрсәтә. Ни өчен ул кушымча йомшак булырга тиеш дигән сорау туа. Ә сингармонизм законы? Гомумән, рус теленннән һәм рус теле аша кергән сүзләрне, башка шундый алынмаларны, кайбер галимнәр тәкъдим иткән аерым очракларга ияреп, татар теленә хас әйтелеш һәм язылыш кагыйдәләренә буйсындыруга таба барабызмы, әллә, күптәннән кабул ителгән кагыйдә нигезендә, чыганак телдәгечә, үзгәртмичә, инде телебездә дә озак вакыт кулланылып ныгыган шәкелдә, безгә таныш сурәттә калдырабызмы?! Абсолют күпчелек очракта мөгез чыгаруның кирәге юк. Ә менә фәнни эзлеклелек мәсьәләсен гел кайгыртып тору шарт.

Инде кайбер очраклар, имеш, сингармонизны саклыйбыз дип, абсурд дәрәҗәсенә җиткерелә. Бөтен йомшак нигезле дип уйланылган яки шулай кебек тоелган алынмаларга йомшак кушымчалар гына кушу тәкъдим ителә. Чагыштырып карагыз: Ямашев-**лар** /-**ләр**, татар әдәбия**-ты** / **-те,** ләкләк кауры́е-**ның** / **-нең** төсе, повесть**-лар / -ләр**, лагерь**-да /- дә**, декабрь-**дә** / **-да,** январь**-дә / -да,** гыйнвар-**да**. Алай гына да түгел, *Киевкә, Киевтән, китләр, чиннәр* һ.б.ш. сүзләрнең «яңа» язылыш, «яңа» төрләнеш үрнәкләрен норма итәргә тиеш булабыз.

Шул ук вакытта, әйтелеше белән язылышы арасында сизелерлек аерма булган сүзләр дә аз түгел. Әйтик, *вазифа, поши* кебек сүзләрне кайбер сүзлекләрдә әйтелешкә якынлаштырып язу вариантары тәкъдим ителде, ягъни: *вазыйфа, пошый* шәкелендә. Газета-журналларда да алар шул

язылышта ныгый баралар. Охшаш мисалларны күпләп китерергә мөмкин (*тарихи – тарихый, рухи – рухый* һ.б.). Ләкин мондый бирелеш норма буларак кабул ителә икән, барлык башка охшаш очракларда да теге яки бу сүзне язуга бертөсле якын килергә тиеш булабыз. Чагыштырыгыз: *хис – хыйсь, сыр – сыйр* һ.б. Ничек кенә булмасын, иң мөһиме эзлекле фәнни караш, ә ул һәрвакытта да саклана дип әйтеп булмый.

Дәвам итеп, [э] фонемасының ике төрле хәреф белән күрсәтелүе очрагы: сүз башында килгәндә **э** хәрефе аша (*эш, эт, энә*), сүз уртасында һәм сүз ахырында килгәндә **е** хәрефе аша (*кеше, тешсез*). Бу сүзләр озак вакыт дәвамында безнең аңыбызга нәкъ менә шул шәкелдә кергән, сеңгән, ныгыган, аларның сурәте хәтергә шулай уелып калган. Шуңа да карамастан, әллә бу очракларны да, кайберәүләр уйлаганча, ансат кына бердәйләштереп куябызмы: *тэшсэз кэшэ эшэ*?! Югыйсә, фонетик закон шуны таләп итә: бер хәрефкә бер аваз, бер авазга бер хәреф...

Тагын бер «бәхәсле» мисалны телгә алып китәргә кирәк. Татарча әйтелештә дә, язылышта да график омоним парлары булган *бак* (кара әле), *кабак* (яшелчә), *кабак* (күз өслеге алмасын каплый торган тире җыерчасы), *табак* (савыт) кебек сүзләр бернинди бәхәс тудырмый булса кирәк. Сүзләрнең ахырында калын әйтелешле арткы рәт [қ] тартыгы килә. Бу сүзләр белән график омоним парлар тәшкил иткән, ягъни язылышы белән охшаш, ләкин әйтелешендә аерма булган *бак* (савыт), *кабак* (мәйханә), *табак* (тәмәке) сүзләрен куллануда да артык кыенлыклар юк. Мисалларның соңгы иҗегендә алгы рәт [к] тартыгы килә. Омонимнарның кайсы варианты күз уңында тотылганлыгын күпчелек очракта сөйләм контексты ачыклый. Ә менә шул ук «орфографик» рәттә торган *казак* (халык атамасы) сүзенә җиткәч, күпләр абына башлый: ахырдан калын иҗеккә кабаттан калынлык билгесе өстиләр, ягъни *казакъ* дип язалар. Янәсе, ул икенче бер сүздән – рус *казак* (борыңгы төрки телдән (!) «ирекле кеше» мәгънәсендә; икесе дә – бер үк тамырдан!) сүзеннән аеру өчен кирәк. Мондый «фәннилек» – аеруча нәшрият хезмәткәрләренә хас күренеш. Мантыйкка нигезләнеп эш йөрткәндә, югарыда китерелгән бер төркем сүзне *табакъ* (савыт), *кабакъ* (яшелчә), *коштабакъ* (тәлинкә) дип язу кирәк булып чыга. Безнеңчә, болай язу дөрес юл түгел.

Г.Ибраһимов иҗат иткән мәгълүм әсәрнең исемендәге *казак* сүзен калынлык билгесе белән язу, бигрәк тә әдәбият галимнәре арасында, – шулай ук гадәти күренеш. Хәлбуки Г. Ибраһимовның әсәре гарәп язуында язылган. Гарәп язуында каты һәм йомшак «к» ике төрле языла. Латин шрифтына күчкәч тә бу ике авазга ике хәреф билгеләнә. Кирил хәрефләренә күчкәч исә каты «к» да, йомшак «к» да бертөрле языла башлый. Г. Ибраһимовның әсәре кирил хәрефләрендә беренче тапкыр 1956 елда басылып чыга, аннары ул тагын берничә мәртәбә дөнья күрә. Әлеге басмаларның барысында да әсәрнең исеме «Казак кызы» дип бирелә. Гомумән, *казак* сүзенең язылышы 1990 елларга кадәр бернинди сорау тудырмаган. Соңгы ярты гасыр дәвамында

басылган сүзлекләрдә – 1966 елгы Татарча-русча сүзлектә дә, 1977–1981 елларда дөнья күргән 3 томлык аңлатмалы сүзлектә дә, соңрак эзлекле рәвештә 2005 елгы аңлатмалы сүзлектә дә, 2002 елгы орфографик сүзлектә дә – бу ике халыкны белдергән берәмлек ике омоним сүз итеп бирелгән. Шуңа күрә традицион рәвештә шул эзлеклелекне саклаганда, бернинди калынлык билгесе («ъ») дә куела алмый.

Сүзләрнең традицион әйтелеше-язылышы шул шәкелдә урнашып, күп еллар дәвамында ныгыган, ул шулай калырга тиеш. Билгеле, бу күренешләр инде күптәннән фәнни нигездә дә, ягъни һәм этимологик, һәм фонетик, орфографик яссылыкларда да шактый тәфсилле һәм ышандырырлык итеп шәрехләнгән [Әхмәтьянов, 2001: 272].

Гомумән, алфавитны алмаштыру белән генә орфографиядәге электән килгән һәм яңадан туачак бәхәсле моментлардан качып булмый. Алфавит проблемасы, дөрес язу кагыйдәләрен фәннн нигездә эзлекле тикшереп ныгыту, шул кагыйдәләрне хөкүмәт дәрәҗәсендә раслатып гамәлгә кертү, иң элек мәгариф системасында куллана башлау, билгеле, үтә катлаулы, каршылыклы бурычлардан санала.

Безнең карашыбызча, бүген орфография мәсьәләсе фәнни булудан бигрәк сәяси һәм икътисади бер проблема (кыска вакыт эчендә күпме дәреслекләр яңадан нәшер ителергә, татарча документлар үзгәртелеп эшләнергә тиеш һ.б.). Шуның өчен, әгәр кириллицаны камилләштерү турында сүз бара икән (бүгенге сәяси-икътисади вазгыятьтә ул – иң дөрес юл), бу мәсьәлә эзлекле фәнни нигездә хәл ителергә тиеш. Дөньядагы күп кенә дәүләтләрнең тәҗрибәсенә таянып, шунысын да истә тоту шарт: тел галимнәре нинди генә нәтиҗәләргә килсәләр дә (билгеле, ул бердәм караш булырга тиеш!), телне куллану, аеруча алфавит мәсьәләсен принципиаль нигездә хәл итү, сәяси яссылыкка күчерелеп, ясалма киртәләргә төртелеп кала. Һәвәскәрлек исә, сәнгать өлкәсендә хупланса да, фән өлкәсендә бер кирәкмәгән буталчыклык яки сүз куертуга гына кайтып кала.

## Әдәбият


Асылгәрәев, Ш. Н. Татар теленең алфавиты һәм орфографиясе турында / Ш.Н. Асылгәрәев // Фән һәм тел. – 2009. – № 2.

Әхмәтьянов, Р. Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г. Әхмәтьянов. – Казан, 2001. – 272 б.

Тимерханов, А. Ә. Май ботканы бозмаса да... / А.Ә. Тимерханов // Мәдәни җомга. – 2011. – 20 май. – № 20.

Хатипов, Ф. Катлы-катлы алфавит / Ф.М. Хатипов // Мәдәни җомга. – 2015. – 28 ноябрь. – № 47.